Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында
гражданнар җыены
КАРАРЫ

2022 елның 19 ноябре №2

2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлеге Түбән Чыршылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлеге Түбән Чыршылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, срокль хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш ш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру: җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

Түбән Чыршылы торак пунктында урам утларына техник хезмәт күрсәтү;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Түбән Чыршылы торак пунктындагы Тукай урамы, Плетеная урамында вак таш җәелгән юллардагы чокырларны ремонтлау;

Түбән Чыршылы торак пунктында Калмык, Мельничная, Мокрый Куст, Озерная, Плетеная, Совет, Тукай, Үзәк урамнарындагы юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Түбән Чыршылы авылы, Түбән Чыршылы авылы административ бинасында-Үзәк урам, 105 йорт, балалар бакчасы бинасында -Совет урамы, 8 йорт, Үзәк урам, 23 йорт буенча, ФАП бинасында-Мельничная урамы, 23 йорт , Мордва Ивановка авылында-авыл клубы бинасында-Горная урамы, 27 йорт, Мордва Ивановка авылында Совет урамы 13 йорт буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Н.Я. Хәйруллина